## Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советы

## КАРАРЫ

Азнакай шәһәре № 176-43 «16» июнь 2020 ел

Аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» күрсәтмәсенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020елның 22 апрелендәге 820-р номерлы күрсәтмәсенә таянып

Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – шәһәр Башкарма комитеты) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре муниципаль милке объектлары булган муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба – муниципаль милек) арендалау шартнамәләре буенча, түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектерүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү, 2020 елның апрель - июнендә кичектереп торылган аренда түләүләрен түләү срогы белән, кичектерелгән аренда түләүләрен түләү вакыты 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча башларга;

б) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар – кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге карар үз көченә кергән көннән әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлне югары әзерлек режимы кертелгән датага торышы буенча муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән арендаторларга – кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә;

б) әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель – июнь айлары өчен аренда түләвен кичектереп торуны һәм аны 2020 һәм (яки) 2021 елларда аренда килешүендә каралган срокларда тигез өлешләрдә түләүне, шулай ук аренда түләүләре суммасын бер тапкыр түләүне күздә тотарга тиеш.

3. Шәһәр Башкарма комитетына әлеге карарның үтәлеше турында 2020 елның II кварталыннан башлап хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин